Кукмара муниципаль районы
Каенсар авыл җирлеге башлыгы карары

16 декабрь, 2025 ел № 2

«Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында» Каенсар авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 17 мартындагы 9 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 6 өлеше, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында» Татарстан Республикасы Президентының 2015 елың 2 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы нигезендә боерам:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында» Каенсар авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 17 мартындагы 9 номерлы карары;

- «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең Каенсар авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 17 мартындагы 9 номерлы карары белән расланган хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Каенсар авыл җирлеге башлыгының 2023 елның 17 июлендәге 3 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

Җитәкче И.Х. Исхаков